ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап һәм 2025 елда Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык доклад турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны һәм 2025 елда Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык докладны карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны һәм 2025 елда Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык докладны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап һәм 2025 елда Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык доклад турында фикер алышуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәләре вәкилләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрне карау һәм кирәкле чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы Рәисенең 2026 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында бәян ителгән бурычларны үтәү максатларында алга таба дәүләт органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итәргә.

3.2. «Россия Федерациясенең 2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага илкүләм үсеш максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указында билгеләнгән Россия Федерациясенең илкүләм үсеш максатларына ирешү өчен ведомствоара нәтиҗәле эшчәнлекне, шулай ук илкүләм проектлар һәм дәүләт программалары үтәлешен мониторинглауны һәм тикшереп торуны тәэмин итәргә.

3.3. 2025 елның 6 декабрендәге 1052 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган 2025 – 2026 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыеннарында, VI һәм VII чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау кампанияләре барышында «Минем депутат» онлайн-сервисы һәм «Мобиль кабул итү» проекты аша, шулай ук Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы Рәисен сайлау кампанияләре барышында кергән мәсьәләләрне хәл итү буенча чаралар комплексына («юл картасына») кертелгән чараларны үтәүне тәэмин итәргә.

3.4. Торак-коммуналь хуҗалыкны модернизацияләү, халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне яхшырту, төп тармак предприятиеләрен кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү эшен оештыруны дәвам итәргә.

3.5. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм алар арасыннан булган хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына, махсус хәрби операциядә һәлак булган һәм хәбәрсез югалган катнашучыларның гаиләләренә аерым игътибар биреп, комплекслы ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә.

3.6. Законнарны даими мониторинглау нигезендә норматив хокукый базаны камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары белән үзара эшчәнлекне арттырырга, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында каралган норматив хокукый актларны үз вакытында кабул итүне тәэмин итәргә.

3.7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны һәм 2025 елда Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында җыелма еллык докладны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга.

Татарстан Республикасы<br>
Дәүләт Советы Рәисе<br>
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре<br>
2026 елның 15 апреле<br>
№ 604-VII ДС